ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ
ВЕТЕРИНАРИИ
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.12.2016 г. Казань № 513-п

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2013 елның 27 маендагы № 165-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүгә карата административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

2016 елның 3 июлендәге «Дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольлекне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» № 277-ФЗ Федераль закон кабул ителү сәбәпле һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең норматив-хокукый актларын законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2013 елның 27 маендагы № 165-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүгә карата административ регламентына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 19.01.2015 № 6-п, 15.12.2015 № 534-п, 12.07.2016 №257-п боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6.3 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле «8)» һәм «9)» кызыл юллары белән тулыландырырга:

«8) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән, рөхсәт итүче документларны да кертеп, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеле бер исемлеккә кертелгән, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагында булган документларны һәм (яки) мәгълүматларны тапшыруны таләп итәргә;

9) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән тикшерүне үткәрә башлау датасына кадәр документлар, мәгълүматлар тапшыруны таләп итәргә. ТР МК БВИ, тикшерү үткәрү турында әмернамә яки боерык кабул иткәннән соң, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматларны соратырга хокуклы.»;

2.1.6 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле кызыл юлларны өстәргә:

«Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләр бозылу очракларын кисәтү, мәҗбүри таләпләрне бозуга сәбәпче булган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару максатларында, ТР МК БВИ, ел саен раслана торган бозуларны кисәтү программасына туры китереп, мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыра.

ТР МК БВИ рәсми сайтында шулай ук түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

- бозуларны кисәтүнең ел саен раслана торган программасы;

- төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелегенең тикшерү предметы аларның үтәлешен бәяләүдән гыйбарәт булучы мәҗбүри таләпләрне үз эченә ала торган норматив-хокукый актларның яки аларның аерым өлешләренең исемлеге, шулай ук тиешле норматив-хокукый актларның текстлары;

- мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр өчен мәгълүмат. Мәҗбүри таләпләр үзгәртелгән очракта, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләрдәге мәҗбүри таләпләрне билгели торган яңа норматив-хокукый актларның эчтәлеге, аларның гамәлгә керү вакытлары һәм тәртибе турында аңлатмалар, шулай ук мәҗбүри таләпләрне кертүгә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән, зарури оештыру, техник чараларны үткәрү турында киңәшләр урнаштырыла;

- төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәҗрибәсен гомумиләштерү (елга бер мәртәбәдән ешрак түгел), юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең бозылуына юл куелмау максатларында күрелергә тиешле чараларга карата киңәшләр белән, мондый бозуларның иң еш очрый торган очракларын күрсәтеп.»;

2.3 пунктында:

2.3.1 пунктчасында «эшләнә торган» сүзләреннән соң «һәм раслана торган» сүзләрен өстәргә;

2.3.2 пунктчасын түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

«2.3.2. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу очрагын юкка чыгару турында элегрәк бирелгән күрсәтмәнең юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан үтәлү вакыты узу;

2) ТР МК БВИ вазифаи затының дәлилле йогынты акты, – юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән хезмәттәшлек итмичә үткәрелгән контрольлек чаралары, гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан ТР МК БВИ килгән мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган

мәгълүматларны карап тикшерү яки беренчел тикшерү нәтиҗәләрен анализлау нәтиҗәсендә, – түбәндәге фактлар турында:

а) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә зыян салыну куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килү;

б) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә зыян салыну, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү;

в) кулланучыларның хокуклары бозылу (хокуклары бозылган кулланучыларның, гражданнарның хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органга мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүченең үзенең бозылган хокукларын яклау (торгызу) буенча юридик затка, шәхси эшмәкәргә мөрәҗәгать итүе һәм мондый мөрәҗәгатьнең карап тикшерелмәгән булуы яисә мөрәҗәгать итүченең таләпләре канәгатьләндерелмәгән булуы шарты белән);

3) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләренә туры китереп һәм прокурорның прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешен күзәтү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы таләбе нигезендә чыгарылган ТР МК БВИ башлыгы әмернамәсе (боерыгы).»;

түбәндәге эчтәлекле 2.3.3-2.3.10 пунктчаларын өстәргә:

«2.3.3. ТР МК БВИ мөрәҗәгать итүченең затын билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук шушы Регламентның 2.3.2 пунктчасының 2 кызыл юлында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләре булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә алмыйлар. Әгәр дә мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат, шушы Регламентның 2.3.2 пунктчасының 2 кызыл юлына туры китереп, планнан тыш тикшерү үткәрүнең нигезе була алса, ТР МК БВИ вазифаи заты, аның мөрәҗәгатьнең яки гаризаның авторына карата нигезле шикләре булганда, мөрәҗәгать итүче затны билгеләү буенча гакыллы чаралар күрергә бурычлы. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, аларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан бары тик бердәм идентефикацияләү һәм аутентификацияләү системасында мөрәҗәгать итүченең мәҗбүри авторлаштырылуын күздә тотучы мәгълүмати-коммуникация технологияләре чараларыннан файдаланып җибәрелгән булу шарты белән генә, планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә алалар.

2.3.4. Шушы Регламентның 2.3.2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турындагы мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, мәгълүматларны карап тикшергәндә элегрәк килгән, охшаш мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны,

мәгълүматларны карап тикшерү нәтиҗәләре, шулай ук тиешле юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә карата элегрәк үткәрелгән контрольлек чараларының нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

2.3.5. Мәҗбүри таләпләр бозылуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат, мәҗбүри таләпләрне бозу турында яисә шушы Регламентның 2.3.2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүматлар булмаганда, ТР МК БВИ вәкаләтле вазифаи затлары тарафыннан килгән мәгълүматка беренчел тикшерү үткәрелергә мөмкин. Беренчел тикшерүне үткәрү барышында гаризаны һәм мөрәҗәгатьне җибәргән, мәгълүмат тапшырган затлардан өстәмә белешмәләр һәм материаллар (шул исәптән телдән тәртиптә) соратып алу буенча чаралар күрелә, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең ТР МК БВИ карамагында булган документлары карап тикшерелә. Беренчел тикшерү кысаларында юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратылырга мөмкин, ләкин мондый аңлатмаларны һәм башка төрле документларны тапшыру мәҗбүри булып саналмый.

2.3.6. Беренчел тикшерү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләр бозылуга юл куйган затлар ачыкланганда, мәҗбүри таләпләрне бозу турында яисә шушы Регламентның 2.3.2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүматлар алынганда, ТР МК БВИ вәкаләтле вазифаи заты, шушы Регламентның 2.3.2 пунктчасының 2 кызыл юлында күрсәтелгән нигезләр буенча, планнан тыш тикшерү үткәрү турында дәлилле йогынты актын әзерли. Беренчел тикшерү нәтиҗәләре буенча юридик затны, шәхси эшмәкәрне җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрелми.

2.3.7. ТР МК БВИ башлыгы, башлыгы урынбасары карары буенча, әгәр дә тиешле тикшерүне башлаганнан соң, аны оештыру өчен нигез булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланса, яисә мөрәҗәгатьтә яки гаризада белә торып ялган белешмәләр булуы ачыкланса, беренчел тикшерү, планнан тыш тикшерү туктатыла.

2.3.8. ТР МК БВИ, әгәр дә гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә белә торып ялган белешмәләр күрсәтелсә, гражданнан, шул исәптән юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән, аталган затлардан килгән гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүгә бәйле рәвештә ТР МК БВИ тарафыннан тотылган чыгымнарны түләттерү турында судка шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2.3.9. ТР МК БВИ тарафыннан юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш урынга чыгып тикшерү № 294-ФЗ Федераль законның 10 статьясының 2 өлешендәге 2 пунктының «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча, мондый юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлекләре гамәлгә ашырылу урыны буенча прокуратура органы белән килештергәннән соң үткәрелергә мөмкин.

Юридик затны, шәхси эшмәкәрне планнан тыш урынга чыгып тикшерүне прокуратура органы белән килештерү турында гариза рәвеше РФ Икътисади үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган.

2.3.10. Әгәр дә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуның ачыкланган очракларын юкка чыгару турындагы күрсәтмәне

үтәү вакыты узу планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен нигез булып торса, ул очракта мондый тикшерүнең предметы булып бары тик ТР МК БВИ биргән күрсәтмә үтәлеше генә тора ала.»;

3 бүлекнең беренче кызыл юлын 3.1 пункт итеп санарга;

5 бүлектә:

преамбулага түбәндәге эчтәлекле 16 нчы кызыл юлны өстәргә:

«Шушы Регламентның 1.6 пунктының 1.6.1 пунктчасындагы «5)» кызыл юл нигезендә ТР МК БВИ ДВИ ТБ вазифаи затлары Россиянең Федераль салым хезмәтеннән түбәндәге документларны һәм (яки) мәгълүматларны сораталар һәм алалар:

- Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан белешмәләр;

- Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан белешмәләр;

- бердәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары реестрыннан белешмәләр.»;

5.1.6 пунктчасының беренче кызыл юлын түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

«5.1.6. Имзаланган әмернамә (боерык) нигезендә тикшерүне үткәрү вәкаләте бирелгән җаваплы башкаручы юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү үткәрү турындагы әмернамәнең (боерыкның) күчермәсен, кулга тапшыру турында белдерүнамә белән, почта аша заказлы хат итеп җибәреп һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм, әгәр дә мондый адрес бердәм дәүләт юридик затлар реестрында, бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрында тиешенчә теркәлгән булса яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан элегрәк ТР МК БВИ тапшырылган булса, – юридик затның, шәхси эшмәкәрнең электрон почтасы адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә яисә башка төрле үтемле ысул белән тикшерү үткәреләчәге турында хәбәр итә.»;

5.1.7 пунктчасының икенче кызыл юлында «Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган тәртиптә» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.1.9 пунктчасының дүртенче кызыл юлын түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә:

«Әгәр дә тапшырылган, элегрәк тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган аңлатмаларны һәм (яки) документларны карап тикшергәннән соң яисә аңлатмалар булмаган очракта җаваплы башкаручы мәҗбүри таләпләрнең бозылу билгеләрен ачыкласа, ТР МК БВИ ДВИ ТБ вазифаи затлары урынга чыгып тикшерү үткәрергә хокуклы. Урынга чыгып тикшерү үткәргәндә юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән документар тикшерү үткәрү барышында алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматларны таләп итү тыела. Урынга чыгып тикшерү үткәрү зарурлыгы турында карарны ТР МК БВИ башлыгы (башлыгы урынбасары) кабул итә.»;

5.2.7 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле кызыл юлны өстәргә:

«Әгәр дә шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазифаи затының булмавына бәйле рәвештә, яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан эшчәнлекнең фактта башкарылмавына

бәйле рәвештә, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазифаи затының бүтән төрле, тикшерүне үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында планлы яки планнан тыш урынга чыгып тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, ТР МК БВИ вазифаи заты, аны үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы сәбәпләрне күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрү момкинлегенең булмавы хакында акт төзи. Бу очракта ТР МК БВИ, тиешле тикшерүне үткәрү мөмкинлегенең булмавы хакында акт төзелгән көннән башлап өч ай дәвамында, мондый юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата, планлы тикшерүне еллык планлы тикшерүләр планына кертмичә һәм юридик затка, шәхси эшмәкәргә алдан хәбәр итмичә, планлы яки планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.»;

5.4.7 пунктчасындагы беренче кызыл юлда «ысул белән» сүзләреннән соң «, шул исәптән, әгәр дә мондый адрес бердәм дәүләт юридик затлар реестрында, бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрында тиешенчә теркәлгән булса яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан элегрәк ТР МК БВИ тапшырылган булса, – көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең электрон почтасы адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә.» сүзләрен өстәргә.

2. Шушы боерыкның 1 пункты 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары А.Н. Гыйбадуллинны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе
башлыгы в.б. А.Р. Гәрәев